**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Янил авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**2021 елның 10 ноябре** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Бөяр поселогы, Чәчәкле ур., 5 йорт адресы буенча урнашкан торак йорт бинасында гражданнар җыены үткәрергә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерларлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Бөяр поселогында юлларны кышын һәм җәен карап тоту (чистарту, кардан арындыру), килешү буенча түләү;
- Бөяр поселогында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Янил авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.
4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы И.Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893